РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраль 2022г. г. Альметьевск № 126

Әлмәт муниципаль районы тарафыннан җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 елеше, Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 06 маендагы 468 номерлы "Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе турында» гы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы составына керүче Габдрахман, Әлмәт, Бишмунча, Бута, Борискино, Баграж-Никольский, Васильевка, Югары Акташ, Югары Мактама, Елховой, Ерсубайкино, Кәләй, Колшәрип, Кама-Исмәгыйль, Кичү, Кичүчат, Клементейкино, Кузайкино, Урман-Кәләй, Миңлебай, Мәмәт, Түбән Абдул, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Яңа Троицкий, Рус Акташы, Иске Михайловка, Сәрән, Селәй, Иске Суркино, Ямаши, Ямаш, Тайсуган авыл җирлекләре, Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетлары вәкаләтләрнең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә:

- җирлекнең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән эш итү;
- җирлекнең муниципаль милке реестрын алып бару.

2. Әлмәт муниципаль районының Башкарма комитетына:

- җирлекләрнең башкарма комитетлары белән килешүләр төзү тәртибенә туры китереп, җирлекләр бюджетларыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән аларның вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру (1 нче кушымта) турында килешүләр төзергә;
- җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына бюджетара трансфертларны бүлү методикалары һәм (яисә) бирү тәртибе нигезендә бюджетара трансфертларның күләмен билгеләргә;
- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан

Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елга,2023 һәм 2024 елларның планлы чорына бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. «Әлмәт муниципаль районы тарафыннан җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләр вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2020 елның 23 июнендәге 378 номерлы Әлмәт муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO. TATARSTAN.RU) һәм һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз кеченә керә һәм үзенең гамәлен 2022 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Мингазов И.М.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2022 елның
28 февралендәге 126 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы ___________авыл җирлеге Советы вәкаләтләренең бер өлешен Әлмәт муниципаль районы Советына апшыру турында килешү

«___» _________ 2022 ел ________ (авыл җирлеге)

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба «районның Башкарма комитеты» дип аталучы, бер яктан, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы_______ авыл җирлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы _______ Башкарма комитеты муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы _______ авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә эш итүче _______ башлык йөзендә, алга таба "авыл Советы башкарма комитеты " дип аталучы, икенче яктан, бергә "Яклар" дип аталучылар, түбәндәгеләр турында Килешү төзеделәр:

1. Килешү предметы

Әлеге Килешүнең предметы - җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру.

- җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт белән эш итү;
- җирлекнең муниципаль мелкәте реестрын алып бару.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлекнең башкарма комитеты районның башкарма комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

- әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм матди ресурслар (алга таба - вәкаләтләр);
- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Җирлекнең башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Килешүнең 5.1 - 5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;
- Әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны район башкарма комитетыннан алырга.

2.3. Районның Башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- кануннар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына тәэмин итәргә;

- җирлекнең башкарма комитетына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисаплар, шулай ук аерым соратулар буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Район Башкарма комитеты түбәндәге хокукларга ия:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын һәм матди ресурсларны алырга һәм кулланырга;

- җирлек башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс акчаларыннан өстәмә рәвештә файдалану.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бюджет законнары нигезендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме Әлмәт муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турындагы карары белән билгеләнә.

Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен әлеге килешүгә кушымта нигезендә билгелиләр.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен бирелә торган финанс чаралары квартал саен тигез өлешләр белән күчерелә.

3.4. Районның Башкарма комитеты финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлекнең башкарма комитеты таләбе буенча җирлекләр бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

4. Матди ресурсларны тапшыру тәртибе

4.1. Районның Башкарма комитеты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру ечен «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 статьясындагы 10 елешенең 5 пункты нигезендә кабул ителгән район Советы карары нигезендә әлеге Килешүгә кул куйган кеннән алып утыз кен эчендә кабул итә, ә җирлекнең башкарма комитеты әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын һәм матди ресурсларны тапшыра.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану шартнамәсе белән билгеләнә һәм аның мөһим шарты булып тора.

4.3. Әлеге Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч рәвештә тезелә һәм әлеге Килешүнең гамәлдә булу чорына төзелә.

5. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору

5.1. Җирлекнең башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, район Башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. Районның Башкарма комитеты авыл җирлеге башкарма комитеты соратып алган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга кереп йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе район Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы һәм районның Башкарма комитеты тарафыннан, шул исәптән җирлек башкарма комитеты таләбе буенча да, гамәлгә ашырыла.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу срогы

6.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2022 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Якларның берсе аны өзү турында әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 кеннән дә соңга калмыйча белдермәсә, Килешүнең чираттагы финанс елына озайтылган дип санала.

## 7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатылырга мемкин:

- Яклар килешүе буенча;
- Бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

7.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче Якка язмача рәвештә, аның гамәлдә булу фаразланган датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты җирлек башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны кире кайтара.

## 8. Якларның җаваплылыгы

8.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

8.2. Әлеге Килешү буенча якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле як икенче якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф сала.

8.3. Штраф түләү яклар әлеге Килешү буенча бурычларны алга таба үтәүдән азат итми.

## 9. Бәхәсне хәл итү тәртибе

9.1 Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сейләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язма рәвештә рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү Якларның һәркайсы өчен бере буенча тигез юридик кечкә ия ике нөсхәдә төзелгән.

11. Якларның имзалары

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе ________________

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
_______авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе______________

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов